Мордовия Росреестрында vз кvчемсез милеклərен (недвижимость) мошенниклардан ничек сакларга икəнлеге турында сойлəделəр.
Проблема бик актуаль, чонки барлык милекчелəрне дə борчый. Мордовия Республикасы буенча Росреестр идарəсе житəкчесе урынбасары Катерина Ручина мошенниклык схемалары еш очрый торган очраклар турында сойлəде һəм vз кvчемсез милегенне яклау максатыннан нилəр эшлəргə кирəклеген анлатты. Кагыйдə буларак, шалтыратучылар vзлəрен Росреестр яки хокук саклау органнары хезмəткəрлəре дип таныштыралар һəм аферистларны тотуда ярдəм тəкъдим итəлəр. Шул ук вакытта милекчегə vз кvчемсез милеген яклау максатыннан ул аны сатарга тиеш, дилəр.
Исегездə тотыгыз: Росреестр хезмəткəрлəре беркайчан да милекчелəргə мондый тəкъдимнəр белəн шалтыратмый.
Үз кvчемсез милегенне ничек якларга? Ин гади ысул - сезнен шəхси катнашыгыздан башка килешvлəрне теркəvне тыю турында гариза бирv. Моны Росреестр сайтындагы шəхси кабинетта, дəvлəт хезмəтлəре порталында яки МФЦда эшлəргə момкин. Гариза бирелгəннəн сон, бердəм дəvлəт кvчемсез милек реестрына (ЕГРН) тиешле язма кертелəчəк. Һəм əгəр Росреестрга документлар милекченен шəхси катнашыннан башка тапшырылса (мəсəлəн, ышанычнамə буенча), алар каралмаячак. Аларны гариза бирvчегə кире кайтарачаклар. Бик моһим!
Игътибар итəбез, Росреестр гражданнарга, аларнын кvчемсез милек объектларына карата электрон документлар теркəлvгə кергəн очракта, һəрвакыт (почта яки электрон почта аша) хəбəр итə. Әгəр Хокук иясе мондый хəбəр алса һəм ул да, анын вəкиллəре дə бернинди документлар бирмəгəн булып чыкса, ул бу хакта Росреестрга оператив хəбəр итə алачак һəм килешv булмаячак.
Бик моһим! Сатучы милекче исеменнəн нотариаль ышанычнамə буенча эш итсə, килешvгə аеруча игътибар итəргə кирəк. Ышанычнамəне Федераль нотариаль палатанын рəсми сайтында тикшерергə момкин.
Уяу булыгыз һəм һəрвакыт нинди документларга кул куюыгызны игътибар белəн тикшерегез. Шуны истə тотыгыз: фатир хужасын ялгыш юлга керткəн һəм ниндидер документ (мəсəлəн, хезмəт кvрсəтvлəр яки кредит килешve очен тvлəv турында квитанциялəр) кыяфəтендə ана имза куярга торак сатып алу-сату килешvен биргəн очраклар була. Кеше карамыйча гына ана кул куя һəм милексез кала. Мондый очрак-ларда зыян кvрvчелəр ешрак олкəн яшьтəге кешелəр була. Мошенник-лык кылмас очен, vзегезнен олкəн яшьтəге туганнарыгыздан һəм якыннарыгыздан игътибарлырак булуыгызны сорагыз.
Мəгълvмат Мордовия Республикасы буенчаРосреестр Идарəсе тарафыннан əзерлəнгəн